ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 23 марты** **Чистай шәһәре** **№ 208**

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның 22 декабрендәге
869 номерлы карары белән расланган
Чистай муниципаль районы авыл җирлекләр
территориясендә ваклап сату челтәрене стационар
булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы
объектларын урнаштыру турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсенең норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында монополиягә каршы законнарны бозу билгеләре булган гамәлләр (гамәл кылмау) туктату турында 2022 елның 3 мартындагы П06/2022 номерлы, 2022 елның 11 мартындагы П06/2022 номерлы кисәтүләрен карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 декабрендәге 869 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы территориясендә ваклап сату челтәренең стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 4.14 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы юридик зат, эшчәнлек төрләренең берсе-ваклап сатуны гамәлгә ашыру, шулай ук «2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 2 өлеше таләпләренә туры килгән затлардан тыш, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә махсус салым режимына күчкән физик затлар, шул исәптән хосусый эшмәкәрләр катнаша ала;

Нигезләмәнең 4.17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль

районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов